


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 4, Декабрь, 2025 ел*

## Яңа ел килә




**Яңа ел** - һәркемнең иң яраткан һәм көтеп алган бәйрәмнәренең берсе. Әмма бу бәйрәм турында без күп беләбезме соң? Яңа ел турында иң кызыклы фактларны җыярга булдык. Яңа елны бәйрәм итә башлау безнең эрага кадәрге 3 меңьеллыкка - Месопотамиягә барып тоташа. Вавилон халкыннан иудейлар, аннары греклар аша бу вакыйга Көнбатыш Европага кадәр килеп житә. Аннары инде Җир шарының башка илләренә тарала.

Яңа елны бәйрәм итү вакыты төрлечә булган. Аны язын да, җәй көне дә, көзен дә, без гадәтләнгәнчә кыш көне дә бәйрәм иткәннәр. Хәзерге вакытта исә күпчелек илләрдә Яңа елны 31 декабрьдән 1 гыйнварга каршы төндә бәйрәм итәләр.

Борынгы Русьтә X-XV гасырда Яңа елны 1 мартта бәйрәм иткәннәр, 1348 елда бәйрәм 1 сентябрьгә күчерелгән, ә 1699 елда Россия императоры Петр I халыкны яңа указы белән шаккатыра. Ул ел башын 1 сентябрьдән 1 гыйнварга күчерә. Бу бары тик календарьдагы дата гына булмасын өчен, үз указында өйләрне чыршы һәм артыш ботаклары белән бизәргә, матур итеп киенергә, мушкетлардан атарга, ракеталар аттырырга боера.

Чыршы бизәү турында беренче рәсми мәгълүматлар XVII гасырга карый. Тарихчылар сүзләренчә, Раштуа уңаеннан беренче чыршыларны Эльзаста бизи башлыйлар. Төсле кәгазьдән ясалган розалар, алмалар, печенье, шикәр кисәкләре һәм мишура беренче уенчыклар була. Россиядә яңа ел чыршысын XIX гасырда да, XX гасыр башында да бик яратып бизиләр. Әмма 1918 елда большевиклар бу гадәтне тыя: әлеге традиция дини бәйрәм - Раштуа белән бәйле дип белдерә. Чыршы бизәү гадәте **1935** елда гына кире кайта.

Беренче пыяла чыршы уенчыгы Тюренгиядә (Саксония) XVI гасырда ясала. Чыршы уенчыкларын күпләп житештерү исә XIX гасырда гына башлана.

Санта-Клаус беренче тапкыр **1822** елда Америка Кушма Штатларында барлыкка килә. Соңрак славян халыклары Сантаны «күчереп алып» безнең Кыш бабайны булдыра.

Дед Морозның туган көне - 18 ноябрьдә. Ышанулар буенча, нәкъ шушы вакытта аның туган ягына - Беек Устюгка карлы-буранлы кыш килә.

Ә менә Кар кызы образы Россиядә уйлап табыла. **1873** елда Александр Островский «Снегурочка» пьесасын яза. Кар кызы, Кыш бабайның оныгы буларак, XX гасырның 50 нче елларында Кремль чыршы бәйрәмнәре өчен язылган сценарийлар аша таныла.

**1843** елда Лондонда беренче яңа ел открыткасы бастырыла. Шул рәвешле, Яңа елга открыткалар җибәреп тәбрикләү традициясе барлыкка килә.Барыбызга да таныш «В лесу родилась ёлочка» җыры беренче тапкыр «Малютка» балалар журналында **1903** елда ук басылып чыга. Бары тик 2 елдан соң гына композитор Леонид Бекман Раиса Кудашева шигыренә музыка яза.

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы, тарих укытучысы**

## МИН ЯҢА ЕЛДАН НИЛӘР КӨТӘМ?

Яңа ел – бөтен дөньяда миллионлаган кешеләрнең иң көтеп алынган бәйрәме. Минем өчен Яңа ел искиткеч бәйрәм. Миңа бигрәк тә бәйрәм алды ыгы-зыгысы ошый: барлык кешеләр дә бәйрәмнәргә әзерләнә, өй бизи, бүләк ясый...

Менә әкренләп безгә Яңа 2026нче ел якынлаша. Анда безне нәрсә көтүе турында фаразлау бик авыр. Элек мин һәрчак алда нәрсә булачагын һәм нәрсәгә әзерләнергә кирәген беләм дип уйлый идем. Әмма узып баручы ел барысы да бездән генә тормавын раслады.

Мин киләсе елдан ни көтәм соң? Иң мөһиме, әлбәттә, сугыш тәмамлануын көтәм. Боларның барысы да төгәлләнгәннән соң яңадан планнар корып, яхшыга өметләнеп булачак бит. Дөнья тыныч булганда гына кешеләр күңеле тыныч.

Әлбәттә, кызыклы сәяхәтләр. Ә мин сәфәрләрне бик сагындым! Машинада еракка барырга яратам. Ыгы-зыгылы шәһәрләр, үзенчәлекле авыллар, төрле музейлар.

Кешеләр Яңа елдан тагын нәрсә көтә? Әлбәттә, шатлык һәм яхшылык. Һәр кеше кебек үк мин дә бары тик яхшылык кына көтәм. Бу ел бөтен дөнья өчен авыр булды, шуңа күрә күпмедер дәрәҗәдә без берләшкәнбездер. Яңа елда барыбыз да исән-сау булсак, шатлансак, якыннарыбызны югалтмасак иде һәм без моңа ирешербез дип өметләнәм. Җәен дә, кышын да барыбыз да урамга чыгуыбызны, киләсе елга күбрәк театрларга йөрүебезне, спектакльләребезне каравыбызны телим. Иң мөһиме, сәламәт булыйк. Барысы да исән һәм сәламәт булса, бөтен хыяллар да чынга ашачак.

Менә шундый минем хыяларым: гади, «жир» хыяллары. Килешәсездер, мин бит күп теләмим. Хәер, юк, әлбәттә, бу бик күп! Чөнки минем теләкләремнең күбесен акчага сатып алып булмый...
Ә сез яңа елданниләр көтәсез?

**Халикова Азалия, 10 нчы сыйныф укучысы**

## Ап – ак карлар



Кар яуганны карадым мин
Тәрәзәдән беркөнне.
Ап-ак ул, бизәкләре
Йолдыз кебек, бик серле.
Кем соң аны ясый икән,
Кем яудырып тора икән?
Ничек куллары туңмый да,
Каян кар житә икән?
Җәйләрен кайда саклыйлар,
Кышын гына яудыргач?
Сорауларым күп, җавабын
Табармын мин укыгач.

**Багавиев Адел, 11 нче сыйныф укучысы**

## Исәнме, Кыш бабай! Сиңа Данис хат яза.

Исәнме, Кыш бабай! Сиңа Данис хат яза. Мин Дусым авылында яшим, Күәм урта мәктәбенең 3 сыйныфында укыйм. Бу хатымны, син атлар белән бүләк таратканда, укырсың дип өметләнәм.

Киләсе яңа елда син ниләр белән безне шатландырырсың икән? Әлбәттә, инде, яңа ел кичендә күңел могҗизалар көтә. Сәгать телләре 12 не сукканда, безгә тыныч тормыш, исәнлек-саулык, бәхетле балачак телисе килә. Барыбызга да киләсе елда зур уңышлар насыйп итсен.

Кыш бабайга хат язарга дигәч, минем уйларым буталып китте. Кыш җиткәч, ак карлар белән чанада тау шуасы килә башлады. Ләкин әле тау ясарлык кар да юк. Яңа ел алдыннан, кешеләр өйләрендә чыршы бизиләр. Мин дә әтиемнән чыршы куюын сорадым. Әтием кибеттән миннән дә зур чыршы алып кайтты. Без аны гаиләбез белән бергә бизәдек. Ул өебез бизәге булып, балкып тора.

Минем 2025 елны бер дә җибәрәсем килми. Елан елы бик күп кызыклы хәлләр, могҗизалар белән истә калды. Ничек кенә булмасын, 2025 елны озатып, 2026 ел - ат елын каршы алырга кирәк.

2026 ел, тәкле аягың белән кил! Илебезгә тынычлык бир, әти-әнидән аерма. Барыгызга да эшләрендә, укуларында уңышлар телим. Кыш бабай, минем язган үтенечләремне кире какма. Сау бул, Кыш бабай!

**Шигапов Данис, 3 сыйныф укучысы**

## Көттергән кыш.

Быел кыш бик озак көттереп килде.Башта көннәр җылы һәм яңгырлы торды, ә аннары инде кинәт кенә суытып, кыш килде. Ул тирә-якны ап-ак карга төрергә теләп көне буе карны яудырды. Эх, рәхәттә соң инде шул вакытта. Урамга чыгасың, кулга бияләйне киясең дә кар тәгәрәтесең. Быел мин каток ясарга да булыштым әле. Мин анда көндә шуарга менәм. Рәхәтләнеп уйныйм, тимераякта җилдертәм генә. Аннары әнием эштән чыгуга: - " Ринат кайтабыз" , дия дә мин өйгә чабам. Эх , рәхәт мизгелләр!

Өйгә кайткач без Ришат белән әнигә ярдәм кулы сузабыз. Аннары дәресләрне карыйбыз. Шулай икенче көн дә җитә һәм без мәктәпкә китәбез. Иртә белән урамда караңгы һәм рәхәт салкынча һава тора. Тиз-тиз генә барырга кирәк. Мәктәпкә житүгә без класска менәбез, анда апабыз белән төрле кызыклы хәлләрне сөйләшәбез. Яңа ел бәйрәменә әзерләнәбез. Менә шулай кайтыр вакыт җиткәне сизелми дә кала.Һәм яңадан мине каток көтә дип мин өйгә йөгерәм.

**Гатауллин Ринат, 5 нче сыйныф укучысы**



## Кыш бабай бүләкләре

Без быел беренче тапкыр мәктәптә Кыш бабай белән Кар кызын каршы алдык. Алар килгәнне зур түземсезлек белән көттек, әниләребез ярдәме белән матур итеп сыйныф бүлмәбезне бизәдек, шигырьләр, җырлар өйрәндек.

Менә ул көн килеп җитте. Кыш бабай белән Кар кызы безгә күп итеп тәмле- тәмле бүләкләр алып килгән иде. Аларга бик зур рәхмәт.

**1 нче сыйныф укучылары**



## Тылсымлы агач сабагы

Безнең авыл клубына Әтнә балалар сәнгать мәктәбенең "Сәхнәдәш" үрнәк балалар театры коллектив килде. Алар Ләбиб Леронның "Чәпәләй һәм Тәпәләй мажаралары"әкиятен күрсәттеләр Балаларның уйнавы миңа бик ошады. Киемнәре,уйнаулары чын артистларныкы кебек.

Ялкау песи белән эт йокларга яраталар.Песи телефонда күп утыра.Тычкан балалары Тәпәләй белән Чәпәләй аларны акылга утыртырга уйлыйлар. Бәйләп куеп,ашарга булалар.Аларны икенче песи коткара.

Тылсымлы агач аларга сабак бирә: "Телефонда утырырга,күп йокларга түгел,хәрәкәттә булырга кирәк,-ди.

Бу сабак безгә дә кирәк.

**Сабирзянов Әскәр 2 нче сыйныф укучысы**




## Дус авырлыкта беленер.

Кеше дуслык белән көчле. Дуслык – кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң күркәм һәм самими бер төре. Дуслар һәрвакыт бер-берләрен аңлыйлар, ярдәмгә ашыгалар, шатлыкны бергә бүлешәләр. Дуслык – ул ике кешенең уртак кызыксынулары, бер-берсе белән ярдәмләшеп, авыр чакта терәк булып яшәүләре. Ул теләсә нинди байлыктан кыйммәтрәк. Дуслык авырлыклар аша сыналырга тиеш. Якын дусларың булганда, сине бернинди каршылыклар да куркытмый. Бергә булганда, теләсә нинди авырлыкларны җиңеп чыгарга мөмкин.

**Мирхазианова Алия, 7 нче сыйныф укучысы**

## Әкият илендә

Без,6 сыйныф укучылары, район күләмендә үткәрелгән елка тамашасын карадык. Әкият илендә сәяхәттә булдык. Яңа ел бәйрәмен һәр кеше көтеп ала, бу бәйрәмнең үз тылсымы бар. Бу бәйрәмгә барлык укучылар теләп катнаша. Быел безнең сыйныф укучылары түгәрәк кысаларында әкият сәхнәләштерде. Без эшебезгә бик тә җаваплы карадык. Төрле рольләр өйрәндек, әкият геройлары булып катнаштык. Матур әкият килеп чыкты. Сәхнәдә чыгыш ясарга түгәрәк җитәкчесе Садриева Алия апа өйрәтте. Ул безгә сәнгатьле итеп сөйләргә, сәхнә хәрәкәтләре эшләү серләрен аңлатты. Чыгышыбыз белән бәйрәм рухы барлыкка китереп, тамашачы каршында чыгыш ясадык. Әкият үзебезгә дә ошады. Тамаша карау ул ял итү булса, ә үзең тамаша әкият куеп чыгыш ясау бик тә җаваплы икән. Спектакль әкият белән чыгыш ясау. Төрле костюмнар хәзерләү дә безгә бик ошады. Киләчәктә тагын тырышып яңа чыгышларга әзерләнербез. Яңа елда яңа максатлар, яңа эшләр, яңа уңышлар булсын.

**Хасбиуллина Илзирә, 6 нчы сыйныф укучысы**